ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
III чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
III созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

КАРАР
от 28.04.2020г

РЕШЕНИЕ
№46-09

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 03.03.2000 ел, №95 Татарстан Республикасы Законының 38 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Актаныш районында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Д.Р. Касыймова, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, аның ярдәмчеләре эшчәнлеге, муниципаль район территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Районның җирле үзидарә органнарына, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау учреждениеләренә, «Ак калфак» иҗтимагый оешмасына, районның иҗтимагый Советына авыр тормыш һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән социаль-тернәкләндерү чараларын иртә ачыклау һәм тормышка ашыру буенча максатчан эш алып баруны йөкләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы урынбасары, Актаныш муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Р.Ф.Галимҗановага йөкләргә.

Совет Рәисе
Актаныш муниципаль районы Э.Н.Фәттахов